Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

6 февраль 2020 ел № 148

«Машиналар керү юлы. ГПС «Әлмәт» Төзелеш» объекты өчен территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Транснефть-Прикамье» акционер җәмгыяте мөрәҗәгате нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын аерып чыгару максатларында,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге территорияләре буйлап уза торган «Машиналар керү юлы. ГПС «Әлмәт» Төзелеш» объекты өчен «Транснефть-Прикамье» акционерлык җәмгыятенә үз акчалары исәбеннән объектка территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын әзерләүгә керешергә тәкъдим итәргә (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.


5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
«06» февраль № 148 карарына
1 нче кушымта

.

«Машиналар керү юлы. ГПС «Әлмәт» Төзелеш» объекты
өчен территория чикләре




Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косарев